Хатыйп Миңнегулов

# Әдәбиятыбызның мәркәзи мөнбәре

(2010 елда “Казан утлары”)

Мәгълүм ки, 1922 елдан бирле төрле исемнәр белән чыгып килүче бүгенге “Казан утлары” (аның быел 1058нче саны дөнья күрде) – татар әдәбиятының һәм гомумән татар рухи тормышының төп журналы, мәркәзи елъязмасы. Башка вакытлардагы кебек, 2010 елда да ул үзенә төшкән бурыч-вазыйфаларны намус белән үтәде, мәдәни тормышны оештыруга һәм үстерүгә, халкыбызны әхлакый-эстетик һәм милли-инсани рухта тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертте. Журнал үз вакытында чыгып барды. Аның тышкы бизәлеше, техник шәкелләшүе әйбәт, зәвыклы. Иллюстратив материаллар, аеруча “Казан утлары” архивыннан” рубрикасы исеме астында бирелүче фоторәсемнәр дә бик урынлы.

Мәҗмуга элек тә, хәзер дә Татарстан, татар яшәеше белән бергә баруны, чынбарлыктагы мөһим иҗтимагый-мәдәни вакыйга-хәлләрне чагылдыруны үзенең төп бурычларыннан берсе дип саный. Билгеле булганча, 2010 елда Татарстан АССРның төзелүенә 90, республикабызның суверенлыгы турында декларация кабул ителүгә 20 ел тулды. Татар дәүләтчелек тарихының мөһим баскычларын тәшкил иткән бу мөһим вакыйгалар Индус Таһиров һәм Рабит Батулла язмаларында (4, 8 нче саннар) шактый тулы чагылыш тапты. Бөек Җиңүгә 60 ел тулуга да журнал үз сәхифәләрен даими рәвештә биреп барды.

Җанисәп алу патша заманында да, хәзер дә халкыбызны борчуга сала, аның күңелендә шик-шөбһәләр уята. Дамир Исхаковның “Татар юлы такыр түгел” исемле фәнни язмасында (9-11 нче саннар) татарның этник тарихы, халыкны исәпкә алу һәм сәясәт мәсьәләләре тулы һәм ышандырырлык итеп яктыртыла.

Халкыбызның милли үзанын кузгату һәм үстерү аша җанисәпкә әзерлек эшендә иҗат әһелләребез дә актив катнашты. Бу яктан шагыйрь Роберт Миңнуллин аеруча өлгерлек күрсәтте. Ул татар тематикасына махсус

шигырьләр циклы иҗат итте, матбугатта, радио-телевидениедә чыгышлар ясады. Шагыйрьнең 8 нче санда басылган “Татар киңлекләрендә” исемле шигырьләр көлтәсе – шуның күркәм бер үрнәге. Андагы парчаларның һәр юлы татар өчен җан ату, куану, әрнү хисе белән сугарылган. Карагруһчылар, үзенең оппонентлары белән бәхәсләшеп, автор болай ди:

... Бетереп булмый татарны –
Тарихны бозып кына,
Үтереп булмый татарны –
Тарихтан сызып кына ...
Татардан котылалмыйсың,
Татарны куалмыйсың,
Бу татарны тырышсаң да,
Беркая куялмыйсың!
Татар илбасар да түгел,
Юлбасар да, баскын да ...
Безнең бу үз урыныбыз
Якты кояш астында ...

Журналның ахырында даими рәвештә бирелеп баручы хроника өлеше дә Татарстан, ил, милләтебез тормышын, әдәбият һәм сәнгатьтәге яңалыкларны күзалларга ярдәм итә.

* * *

“Казан утлары” – барыннан да элек әдәби мәҗмуга. Аның сәхифәләрендә әдәби әсәрләр элек-электән төп урынны били. Журналның 2010 елгы саннары да бу традициягә тугрылыклы калган. Шунысы куанычлы: Рауль Мирхәйдәровның “Җәяүле сәйран” һәм Әхәт Мушинскийның “Һаваларда – ак күгәрчен ...” романнарын исәпкә алмаганда (боларның авторлары да “урыс телле татарларыбыз”), мәҗмугада дөнья күргән әсәрләр үзебезнең газиз татар телендә иҗат ителгәннәр. Бу исә үзе бер куаныч. Чөнки кайбер халыклардагы кебек, “тәрҗемә”гә генә калсаң, эшләр хәрап булачак. Журналда йөздән артык авторның язмасы урнаштырылган.

(Арада икешәр-өчәр мәртәбә чыгыш ясаучылар да бар). Шуларның берничәсеннән (Фатыйх Кәрим, Хәсән Туфан, Җәмал Вәлиди, Нәҗип Думави, Роберт Әхмәтҗанов, Барлас Камалов) калганы, ягъни төп өлеше – бүген исән-сау яшәүче әдипләр. (Бу да сөенечле хәл!). Димәк, мәҗмугада хәзерге татар язучыларының күпчелеге катнаша. Алар арасында Әхсән Баян, Адлер Тимергалин, Туфан Миңнуллин, Мәдинә Маликова кебек өлкән буын вәкилләре дә, Эльвира Һадиева, Рүзәл Мөхәммәтшин, Булат Ибраһим, Рамилә Майорова, Лениза Вәлиева кебек әле яңарак кына әдәбиятка аяк баскан каләм әһелләре дә бар. Журнал, (аеруча шигърият бүлеге мөхәррире Рәдиф Гаташ) гомумән яшь иҗат көчләрен барлауга, үстерүгә һәрчак игътибарлы. Мәҗмуганың “Ак җилкән” башастында яшь авторларга урын бирүе дә хуплауга лаек. Журнал, элеккеге еллардагы кебек, Татарстанда гомер кичерүче каләм әһелләре белән генә чикләнми. Быел аның битләрендә Рим Идиятуллин, Иделбикә, Фәнис Фәтхи, Илдус Фазлетдинов кебек башка төбәк (нигездә, Башкортостан) әдип-галимнәре дә чыгыш ясады.

“Казан утлары”, җанлы әдәби процесс-хәрәкәткә нисбәтән, сүз сәнгатенең өч төренә дә (проза, шигърият, драма) һәм алардагы күпчелек жанрларга да (роман, повесть-бәян, хикәя, кыйсса, очерк, поэма, газәл, робагый, комедия, драма һ.б.) урын бирде. Бу язмаларда аларның һәммәсенә дә тукталу, хәтта барлык исем-атамаларны телгә алу да мөмкин түгел. Биредә без журналдагы әсәрләрнең тик кайберләренә генә кагылып, алар хакында үзебезнең аерым фикер-күзәтүләрне бәян итү, шәхси мөнәсәбәтне белдерү белән генә чикләнербез.

Меңъеллык татар сүз сәнгатендә күп гасырлар буе шигърият хакимлек итте, чәчмә әдәбият-проза икенчел урында кала килде. Драма төре исә XIX йөз ахырында гына тернәкләнә башлады. Узган гасырның тәүге чирегендә, чынбарлыктагы шаулы тормышка нисбәтән, боларның өчесе дә нык үсеш алды. Алга таба проза әкренләп лидерлыкка дәгъвасын арттыра барды. Бу тенденция хәзер дә дәвам итә. Без моны журналның 2010 елгы саннарында да ачык күрәбез: 6 роман, 7 повесть-бәян, дистәләгән хикәя. Аларның икесен

Камил Кәримов (элеккеге традиция белән әйтсәк – Камил Питрәчинский Шалинский) язган. Бу автор гомумән соңгы дистә елда бик нәтиҗәле эшли: әсәрләре (“Ком сәгате”, “Сакау күке”, “Уен” һ.б.) бер-бер артлы басылып тора. Бер интервьюсендә ул “Һәр әсәремдә мин бар” дип әйткән иде. Чыннан да К.Кәримов язмаларында авторның кабатланмас шәхесе, тел-стиль осталыгы, тәнкыйди-юмористик фикерләве ярылып ята. “Игезәкләр йолдызлыгы” романы (9-10нчы саннар) әдипнең иҗади яктан тагын да үсүен, остаруын күрсәтә. Бу – бер. Икенчедән, ул хәзерге татар прозасының мөһим бер уңышы да булып тора.

“Игезәкләр йолдызлыгы” – берничә катламлы, хәзерге иҗтимагый-социаль һәм милли яшәешне гәүдәләндергән мавыктыргыч әсәр. Хронотопик яктан ул Г.Ибраһимовның “Тирән тамырлар” романы кебек фаҗигале вазгыятьтән башланып китә: тормыш үзәгендә кайнаган журналист Шәех Нурны билгесез шартларда кыйнап үтерәләр. Тикшерү башлана. Мәетне җирлиләр. Романда берничә мәртәбә аерым кешеләрнең бер-берсенә охшашлыгы, игезәклек хакында сүз бара. Бу юкка гына түгел икән: баксаң, әсәрнең төп каһарманы исән кала, фаҗигага аңа охшаган башка кеше дучар була. Әсәрнең жанрын автор “роман-фарс” дип билгеләгән. Бу атама чыннан да язманың рухына, эчтәлегенә туры килеп тора. Болай да гайре табигый хәлләргә, инсани һәм әхлакый кысалардан чыккан күренешләргә бай бүгенге тормыш автор тарафыннан тагын да кискенәйтелә, хәтта урыны белән трагикомик, сатирик дәрәҗәгә җиткерелә. Укучы әсәрдә билгеле бер дәрәҗәдә таныш вазгыять, шәхесләр белән дә очраша. Роман, ничектер, хәзерге яшәеш-мәгыйшәтне социологик-эстетик тикшерү рәвешендә дә кабул ителә. К.Кәримов үз каһарманнарының холык-фигылен, шәхси сыйфатларын бирүдә аерым детальләрдән, тел-стиль элементларыннан оста файдалана. Урыны белән әсәрдә логик-психологик яктан дәлилләнеп җитмәгән эш-гамәлләр дә очрый. Кайвакыт автор тел стихиясенә артыграк та бирелә; тәнкыйть, юмор белән мавыгыбрак киткән юллар да күзгә ташлана. Шәт,

журнал вариантын китап итеп әзерләгәндә әдип үз әсәрен әле янә ныклап карап чыгар. Романны дәвам итү мөмкинчелеге дә бар.

К.Кәримовның 1-2нче саннарда нәшер ителгән “Күрше авыл кызы” бәяны да укыла, мавыктыра. Автор анда яшүсмерләрнең эчке дөньясын, психологиясен, тәүге мәхәббәт хисләрен, гыйшкый маҗараларын самими, җылы һәм тәэсирле итеп гәүдәләндерүгә ирешкән. Повестьта пейзаж бирелешенең матур үрнәкләре бар. Гомумән, табигать күренешләрен әсәрнең эчтәлегенә, каһарманнарның рухи халәтенә тапкыр рәвештә оста итеп бирү журналдагы күп кенә башка әсәрләрдә күзәтелә.

Зәки ага Зәйнуллин, чагыштырмача өлкән яшьтә булуына да карамастан, иҗади эшчәнлеген һич тә киметми (Ходай үзенә исәнлек бирсен!): милли хәрәкәттә дә актив катнаша, чәчмә, драма әсәрләрен дә язып кына тора. “Казан утлары”ның 2010 елгы 11-12 нче саннарында аның бик гыйбрәтле бәяны басылып чыкты. Аның үзәгендә - Эстерлебаштан 1907 елда армиягә алынып, Керчь крепостендә 4 ел буе хезмәт иткән Лотфулла солдат. Кырыс, авыр шартлар. Татарларга икеләтә кыенлык. Әмма төп каһарман, авторның үзе кебек, тәвәккәл, баш бирмәс, тырыш, хезмәт сөючән. Шуңа күрә Лотфулла солдат үзенең татарлыгын, динен теләсә нинди шартларда да саклап кала. Ул оста төзүче, артиллерист буларак таныла, унтер-офицер дәрәҗәсенә күтәрелә. Аның белән хәтта югары дәрәҗәле офицерлар, командирлар да хисаплаша. Бу төр образның милли тәрбия ягыннан да әһәмияте зур. Ул - үз-үзеңне, татарлыгыңны тиешле югарылыкта тотуның күркәм бер үрнәге. Бәянда Кырым татарларының тормыш-көнкүреше, тарихы хакында да мөһим факт-мәгълүматлар бар. Баксаң, атаклы Петр Беренче “ике айдан артык” Кырым татарларында әсирлектә булган икән (11 сан, 12-13 б.). Тарихта бик мактала торган Суворов 1782 елда Алупка шәһәрендә 400 артык мулланы “муеннарына таш бәйләп, Кара диңгезгә батырып үтертә” (11нче сан, 14 б.).

З.Зәйнуллин – Лотфулла солдатның улы. Бу әсәре белән автор әтисенә һәйкәл куеп, чын мәгънәсендә үзенең бөек инсани-әхлакый бурычын да үтәгән.

Шамил Бикчурин, Җәмит Рәхимовлар вафатыннан соң Лениногорск төбәге, ничектер, бераз тоныкланып калган иде. Шөкер, бу вакытлы гына күренеш булган. “Казан утлары”ның 2010 елгы саннарында Альберт Хәсәновның “Данәгөл” (7-8 нче саннар), Рәмзия Габделхакованың “Тау артында кояш бар” (4-7 нче саннар) романнары басылу бу төбәктә янә көчле иҗади вазгыять тууын раслап тора. Һәр ике әсәр дә кыска гына вакыт эчендә укучылар тарафыннан яратып кабул ителде. Каләмдәшләре дә, журналист халкы да аларга игътибар итте.

Ике роман да җанлы, бай әдәби тел белән иҗат ителгән. Икесенең дә үзәгендә - соңгы дәвер тормышы, гыйбрәтле язмышлар, катлаулы һәм каршылыклы тереклек-мәгыйшәт, мәхәббәт тарихлары.

“Салкын сугыш” елларында СССР Хәрби диңгез флотының капитан Соболь җитәкчелегендәге “Сергей Киров” крейсеры Франциянең Марсель портына тәүге дуслык визиты белән килә. Анда өлкән матрос булып хезмәт итүче Таһир Туктамышевны Шөһрәт Нугайбәк дигән татар кешесе, капитаннан рөхсәт алып, үзенә биш көнгә кунакка алып китә. 12 яшендә вакытта бу зат, Идел буенда күмәкләшү башлангач, әтисе белән чит илгә китә. Әүвәл Финляндиядә, аннан Бельгия, Германиядә яши. Инде 18 еллап “Марсель портындагы консуллыкта төрек, урыс, фин, гарәп, алман, инглиз , швед телләре буенча тылмач булып” эшли (7нче сан, 39 б.). Тормышлары шактый көйләнгән. Алманиядә туган кызлары Данәгөл – рәссам, йорт, хуҗалык эшләрендә әти-әниләренең бердәнбер таянычы. Бу гаиләдә милли рух хөкем сөрә: татарча сөйләшү, җырлау, гореф-гадәтләрне саклау - гадәти нәрсә. Ата-ана Данәгөлне үзебезнең кавем кешесе белән башлы-күзле итәргә тырыша. Инкыйразга төшмәү, милли нәсел-нәсәбне дәвам иттерү – аларның асыл максаты. Таһир белән Данәгөл арасында мәхәббәт. Төрек мулласы аларга никах та укый. Әмма Таһир, хәрби антына тугрылыклы калып,

крейсерына кайта. Алда ничек булыр, - анысын автор вәгъдә иткән икенче китап күрсәтер.

Мөһаҗирлеккә эләккән татар кешесенең рухи халәте, җирсүе безгә инде билгеле бер дәрәҗәдә Г.Исхакый, Хөсәен Габдүш, Сания Гыйффәт, Хәсән Хәмидулла, Миргазиян Юныс (“Безнең өй өянке астында иде ...”) һәм кайбер башка әдипләрнең әсәрләре аркылы таныш А.Хәсәнов та шул традицияне уңышлы дәвам иттерә. Авторның вакыйга-хәлләрне шул чор вазгыятен, идеологиясен исәпкә алып тасвирлавы да игътибарга лаек. Ул диңгез флотына, техникасына кагылышлы предмет-төшенчәләрне дә шактый өйрәнгән; геройларның рухи халәтен, уй-кичерешләрен, хәрәкәт мантыйкларын да ышандырырлык итеп сурәтли белә.

Р.Габделхакова романының үзәген Наргизә язмышын сурәтләү тәшкил. Ул – гадәти авылда туып үскән гадәти татар кызы. Автор аны үсмер вакытыннан алып тасвирлый: мәктәп укучысы, Казанда училище студенткасы, аннан - Әлмәттә балалар бакчасында тәрбияче. Шушы елларда аның әнисе үлә, әтисе яшьли сөйгән кызына өйләнә. Кифая исемле бу хатын үзе ияртеп килгән баласын, иренең улын һәм кызын тәрбияләргә омтыла. Әмма Наргизә аны кабул итми. Женя исемле урыс егетенә мәхәббәте дә күңелсез һәм ямьсез тәгәлләнгәч, дөньясына ачу итеп, беркемгә белдертмичә, Кыргызстан тарафларына, әнисенең Фатыйма исемле туганы янына китеп бара. Әтисе, туган ягы өчен хәбәрсез югалган бу зат Урта Азиядә 7 ел яши, балалар бакчасында эшли; Янгураз исемле кешегә мәхәббәте фаҗигале тәгәлләнә. Урта Азиядә ыгы-зыгылар башлангач, ягъни узган гасырның азакларында Наргизә туган ягына әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Инде әтисе дә вафат. Шуннан кыз кайчандыр үзе чит күргән үги анасы янына сыена. Олы җанлы Кифая ханым аны һич авырыксынмыйча кабул итә.

Автор Наргизә тормышы аркылы чынбарлыкның, милли яшәешнең күп кенә якларын да яктыртуга ирешкән. Әдип үз каһарманын бизәү, идеаллаштыру, аның эш-гамәлләрен аклау юлы белән бармый. Ул кызны табигатенә хас яшәештә, хәрәкәттә, хаталары, кимчелекләре, шатлык-

куанычлары, үкенеч-газаплары белән күрсәтә. Авторның хатын-кыз булуы Наргизәнең – үз төрдәшенең – психологиясен, ир-ат әдипләре тәмам ачалмаган уй-кичереш дөньясын шактый белеп, үтемле шәкелдә гәүдәләндерүгә булышкан.

Тауларның төрлесе бар: тәбәнәкләре дә, әкияти Тянь-Шань кебекләре дә. Яшьтән үк алар белән сихерләнгән Наргизә тауларның күбесен күрә. Әмма туган як таулары, аның кояшы, яшьли сөйгән яр бер генә. Шактый буталып, адашып йөргән кыз да бу хакыйкатьне ахыр чиктә аңлый. Әсәрнең балалар тудыру йортында тәгәлләнүе дә мәгънәле. Яңа туган малайның әтисе дә - әллә кайдагы Женялар, Янгуразлар түгел, ә Наргизәнең балачак дусты, гомере буе аңа тугрылык саклаган Сәлим.

Р.Габделхакова бу романы белән үзенең җитлеккән, сәләтле, иҗади мөмкинлекләре зур әдип икәнлеген күрсәтте. Аңа уңышлар телибез.

Моңа кадәр сатирик-юмористик шигырьләре, хикәяләре, очерклары белән мәгълүм булган Дамир Гыйсмеддин “Казан утлары”нда тәүге мәртәбә үзенең повесть-бәяны белән чыгыш ясый (11 нче сан). Күләме белән ул артык зур булмаса да, эчтәлеге, мәгънәсе белән шактый тыгыз. Әсәрнең төзелеш-структурасы төп герой – Маратның Киевтән Мәскәү аша Казанга кайтуына корылган. Гадәттә, адәм баласы юлда барганда уйлана. Бәян каһарманы да үзенең бала, егет чакларын, истәлекле вакыйгаларны, гомер борылышларын искә төшерә. Әмма үткәннәрнең кайтавазы аның бүгенгесе белән дә керешеп китә. Язмада соңгы чорның болгавырлары, сәяси фаҗигаләре, милли хәрәкәт, хәтта аерым реаль шәхесләр дә (генерал Дудаев һ.б.) гәүдәләнеш тапкан. Бәянның исеме үк мәгънәле: “Божра буйлап”, ягъни яшәеш, гомер юлы да, поездда барган кебек. Бу “поезд – гомер машинасы” бара да бара. “Безгә хәтле дә йөргән, бездән соң да тәгәри. Аның тукталыш-станцияләре дә бер: “Балачак”, “Үсмерчак”, “Яшьлек” ... “Картлык”. Ахыргысы – “Әҗәл”. Поезд үз пассажирларын шунда төшерә дә, божра буйлап янә “Балачак”ка кайта, кабат алга бара башлый (64-65 б.).

“Игезәкләр йолдызлыгы”, “Тау артында кояш бар”, “Божра буйлап” роман-повестьләре төрле темага язылсалар да, аларны якынайта торган күренешләр дә бар. Ул – хәзерге чынбарлык өчен хас булган җинаятьчелек, әхлаксызлык, алдау, мәкер. Ринат Мөхәммәдиевнең беренче карауга экзотик тоелган “Кыргый атауга сәяхәт” исемле хикәясе дә (аны кечкенә бәян дип тә атарага мөмкин) (9 нчы сан) үзенең асылы белән шул төр әсәрләр белән керешеп китә. Язма реаль фактка нигезләнгән. Автор, Рәчәй язучылар берлеге вәкиле буларак, Яңа Зеландиягә бара. Хуҗалар тәкъдиме белән ул бер атауга сәяхәт кыла. Шунда шактый серле, экзотик шартларда үзенең ике ватандашын очрата. Аларның берсе – Айрат – авторның якташы да булып чыга. Ни өчен бу затлар бирегә эләккән? Баксаң, бизнес белән шөгыльләнгән Айрат белән ярым гарипләнгән Сергей Иванович бу атауга илдәге эзәрлекләүләрдән, үлем белән янаулардан качып киткәннәр икән. Аларның сөйләгәннәре сәяхәтнамә авторын тетрәндерә. А Хәсәнов романындагы Данәгөлнең әти-әниләре, “Тау артында кояш бар” әсәрендәге Урта Азия татарлары шикелле, кыргый атауда яшәргә мәҗбүр итегән Айратларда да туган җирне сагыну, җирсү хисләре бар. Бу – мөһаҗирлеккә эләккән һәр татар өчен уртак тойгы. Һәркемгә үз туфрагы, үз Ватаны булу кирәк.

Салих Сәйдәшев – XX гасыр татар музыкасының падишаһы. Аның җыр-моңнары XXI йөздә дә яшәвен, күңелләрне дулкынландыруны дәвам итә. Рашат Низами “Сәйдәшнең соңгы елы” исемле бәян-кыйссасында (1, 2 нче саннар) бөек композиторның җанлы образын тудыруда уңышлы гына адымнар ясаган.

Проза никадәр куаласа да, шигърият әле һаман да беренчелек дилбегәсен кулыннан төшерми. Меңъеллык тәҗрибә, Кол Гали, Котб, Мөхәммәдьяр, Кандалый, Тукай, Туфан яулаган биеклек һәм бөеклек бүгенге шагыйрьләрне, спорт термины белән әйткәндә, “формада тотарга”, планканы төшермәскә мәҗбүр итә. Без моны “Казан утлары” журналының соңгы ел сәхифәләрен актарганда да күрәбез. Шигърият һәр санда тиешле урын алган. Аерым номерларда хәтта 4-5әр шагыйрьнең парчалары укучыларга тәкъдим

ителгән. Әйткәнебезчә, алар арасында хәзер иҗат итүче күпчелек каләм әһелләре - өлкәннәре һәм яшьләре дә, ир-атлары һәм хатын-кызлары да бар.

Журнал укучыларына тәкъдим ителгән шигъри текстлар идея-тематикалары, жанр-шәкелләре, эчтәлекләре белән, "чынбарлыкның үзе кебек, төрле. Аларда лирик башлангыч, фәлсәфи уйланулар өстенлек итә. Гәрәй Рәхимнең "Менә шундый хәлләр ..." циклы (12 нче сан) көтелмәгән фикер-сурәтләргә, шигъри алымнарга бай. Шәмсия Җиһангирова парчалары (12 нче сан) экзистенциаль-сызлану хисләре белән өрetелгән. Розалина Шаһиның гыйсьяни рухлы лирик каһарманы җирдәге гаделсезлекләргә, башбаштаклыкка түзә алмыйча бәргәләнә, үзен аңларлык затлар эзли.

Тыгыз шәһәрләрдә тын кысыла ...
Җир селкенә ... телеп йөрәкне ...
Күңел эзли ышанычлы бер йөз –
Тапшырырга өмет-теләкне (12 нче сан, 59 б.)

Флера Гыйззәтуллинаның инсан һәм тереклек, тарих һәм заман, татар язмышы турындагы уй-кичерешләрен үз эченә алган шактый күләмле "Ватан көзгесе" әсәре (7 нче сан) һәм эчтәлеге, һәм шәкел-төзелеше белән шактый үзенчәлекле. Автор аның жанрын "шигъри дастан" дип билгеләгән. Әсәр 13 фасылга бүленгән. Аларның исем-атамалары "Кабатлана тарих", "Тукай моңы аша", "Имгәтелгән хисләр аша", "Кереп киләм ханнар заманына" ..., "Мин кол түгел" ... үзләре үк күп нәрсәгә ишарә ясый. Гомумән, бу дастан-поэма махсус фәнни-тәнкыйди мәкаләгә соралып тора.

Мөхәммәт Мирза, күп төрле оештыру-административ эшләр белән мәшгуль булса да, әдәби иҗатка да вакыт таба. Ул эзләнә, төрле шәкел-формаларны сынап карый, милли тематиканы һәрчак күз уңында тота. Аның икенче санда басылган газәл-робагыйлары өчен хикмәтле сүз әйтү, яшәеш хакында фәлсәфи уйлану хас. Әхсән Баян, Лена Шагыйрьҗан, Клара Булатова, Равил Фәйзуллин, Айдар Хәлим, Гарифҗан Мөхәммәтшин, Ркаил Зәйдулла, Нәҗибә Сафина һәм башкаларның шигырьләре дә кызыклы фикер-күзәтүләргә, деталь-образларга бай.

Шигъри иҗат хакында уйланып, Фәнис Яруллин болай ди:

Күпләр әйтә: роман яз син, диләр,
Вакыйгалар синдә җитәрлек ...
Начармени роман вакыйгасын
Бер шигырем барса күтәреп?! (1 нче сан, 19 б.)

Безнең аерым каләм әһелләре, гәрчә бик нәтиҗәле иҗат итсә дә, әдәби җәмәгатьчелек, тәнкыйть игътибарыннан читтәрәк кала килә. Азнакай якларында яшәп ятучы Илдус Гыйлаҗев – шундыйларның берсе. Мин, шәхсән, аның шигырьләрен кызыксынып, яратып укып барам. Ул акыл иясе кебек уйланып та, яшьләр кебек дулкынланып та яза. Аның гади, ачык фикерле парчаларында, ничектер, күңелне борчыган мәсьәләләргә җаваплар табасың. Шагыйрьнең беренче санда басылган әсәрләре дә күңелгә хуш килә, аларда хәтта гадәти, таныш нәрсәләр дә оригиналь, сәнгати яңгыраш таба.

“Казан утлары”ның соңгы – 12 нче санында “2010 елда журналда басылган әсәрләр исемлеге” бирелгән. Анда Сөләйманның “Кыйбласы” (7 нче сан) “шигърият” төркемендә күрсәтелә. Әмма мин аны “драма әсәрләре” рубрикасына кертер идем. “Кыйбла” – татар сүз сәнгатендә Такташлардан ук килә торган шигъри драманың бер төре. Автор үзе аны “Биләр дастаны” дип тә атаган.

Мәгълүм ки, инде менә дистә елдан артык “Сәләт” исемле балалар-яшьләр лагеры эшләп килә. Җәүдәт Сөләйман – аның оештыручысы, җитәкчесе. “Кыйбла” “сәләт”леләр өчен уздырылып килгән әдәби-музыкаль, тәрбияви чараларның сценарие рәвешендә төзелгән. Аның композитор Мәсгудә Шәмсетдинова язган варианты моннан берничә ел элек сәхнәләштерелеп, тамашачыларга күрсәтелгән иде; ул радио аша да яңгырады, җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителде.

“Кыйбла”, – гәрчә без аны гомуми планда шигъри дастан дип атасак та, үзенең төзелеше, эчтәлеге, жанр табигате белән татар сүз сәнгатендә оригиналь күренеш. Ул – тарихи-мифологик ядкяр. Автор шигъри-драматик тел һәм чаралар ярдәмендә халкыбызның этник (скиф, һун, кыпчак, болгар...)

һәм дәүләтчелек (Һун-сөн, Дәшти-Кыпчак, Болгар-Биләр, Алтын Урда) тамырларын барлый, шулар нигезендә татар кавеменең оешуын-шәкелләшүен ассызыклый. Арага, интертекстуаль ысул белән, легенда-риваятьләр, җырлар да кертеп җибәрә. Әсәрдә, авторның үзе белән бергә, җил, күк иясе, тау иясе, чишмә иясе кебек шартлы-мифологик образлар да, Атилла, Алмас хан кебек тарихи шәхесләр дә катнаша. Нинди генә шартларда да иман-ышанычны саклау, кыйбланы югалтмау – әсәрдәге төп мотивлар. Автор фикеренчә, “татар Рухы”, “татар теле” (Рәхмәт Тәңрем, татар теле өчен / Татар теле – Җиһан ачкычы) – халкыбызның төп кыйбласы.

Сөләйман драмасыннан тыш, “Казан утлары”ның 2010 нчы елгы саннарында янә өч сәхнә әсәре бар: Туфан Миңнуллинның “Мулла”, Ләбиб Леронның “Кычыткан чыпчыгы” һәм Зөлфәт Хәкимнең “Кайда син, Атила?!” ядкярләре. Болар арасында аеруча соңгысы игътибарга лаек (10 нче сан). Автор үзе аны “тарихи драма-роман” дип атаган.

Әсәрнең үзәгендә дөньяны, гавами яшәешне Александр Македонский, Чыңгыз хан, Наполеон кебек үзгәрткән, тетрәткән зат Атилла (IV гасыр азагы – 453) тора. Ул – хәзерге төрки-татарларның борынгы бабаларын тәшкил иткән мәшһүр һуннарның җитәкчеләреннән берсе. Бу легендар шәхес инде менә ничәмә-ничә йөз еллар буе гавам телендә: аны мактыйлар да, яманлыйлар да; әмма аңа беркем дә битараф түгел. Зөлфәт Хәкимнең әсәр исемен сорау һәм өндәү билгеләре белән бирүе дә юкка гына түгел, ә символик, тирән мәгънәле.

Татар сүз сәнгатендә Атилла белән кызыксыну көчәйгәннән-көчәя бара. Мөһаҗир шагыйрь Минһаҗ Исмәгыйли (1910-1995) болай ди:

Татар дисәм, миңа күп көч керә,
Күз алдыма килә Батыйлар.
Җир тетрәтеп йөргән Атиллалар
Нигә, дустым, кабат кайтмыйлар?!

Мөсәгыйт Хәбибуллин күптән түгел генә үзенең “Атилла” романын иҗат итте. Сөләйманның “Кыйбла” әсәрендә бу тарихи зат “һун-кыпчак”

кавемен символлаштырып килә, ерак үткәннең бөек бер вәкиле сыйфатында бүгенге “татар балалары”на мөрәҗәгать итә, аларны “татар рухы”на тугрылык саклап яшәргә чакыра”.

З.Хәким драмасында вакыйга-хәлләр V гасырның урталарында Дунай ярларында, Константинопольдә, хәзерге Италия җирләрендә һәм башка урыннарда бара. Анда императорлар, сарай хезмәтчеләре, гаскәриләр, руханилар ... катнаша. Әсәр масштаблы, фәлсәфи-тарихи-символик эчтәлекле. Автор хөкемдар һәм шәхес, хакимият һәм гавам мөнәсәбәтләре, әхлакый һәм инсани кыйммәтләр хакында уйлана, тарихи тәҗрибә, Атиллалар язмышы аркылы бүгенге җәмгыятьне борчыган сорауларга җаваплар эзли. Әсәр төрле драматик алымнарга, сәнгати чараларга бай. “Кайда син, Атилла?!” – Зөлфәт Хәкимнең генә түгел, гомумән хәзерге татар драматургиясенең яңа бер казанышы. Аны, һичшиксез, сәхнәләштерергә кирәк. Әмма бу изге эш һәм режиссер, һәм актерлар өчен гаять авыр һәм катлаулы булачак. Әйткәнебезчә, Атилла – этник яктан безнең борынгы тарихыбызның бөек бер вәкиле. Элекке чорлар белән чагыштырганда, бүгенге татарның хәле шактый аяныч. Аны ничек бу илдән чыгарырга, ничек итеп татарны данлы тарихына туры килешле дәрәҗәгә күтәрергә? Моның өчен Атиллалар кирәк. Ә кайда соң алар? З.Хәкимнең драмасы укучыны әнә шундый уйларга да этәрә.

“Казан утлары”ның 2009 елгы 9-10 нчы саннарында З.Хәкимнең “Легионер” романы басылган иде. Ул елның иң уңышлы әсәрләреннән берсе буларак танылды. Инде менә 2010 елда оригиналь рухлы драма әсәре дөнья күрде. З.Хәким тулы канлы иҗатта, үсештә (Күз тимәсен үзенә!)

Традиция нигезендә “Казан утлары” фәнни-тарихи, әдәби-тәнкыйди язмаларга да даими урын биреп бара. Боларның инде кайберләре хакында сүз булды. Үзенең “Чәрдән ханлыгы” хезмәте белән (12 нче сан) 2009 елда Фәүзия Бәйрәмова татар укучыларына тарихыбызның билгесез сәхифәләрен ачып биргән иде. Аның декабрь санында (2010) дөнья күргән “Далада – татар курганнары” язмасы да гаять кызыклы һәм гыйбрәтле. Бирედә сүз әби-

бабаларыбызның тарихы белән тыгыз бәйләнешле курган-каберлекләр турында бара. Автор Чиләбе төбәгендә Тамерлан-Кисәнә төрбәсе хакында күп төрле мәгълүматлар бирә. Шунысын да искәртик: фәндә Сәйф Сараиның атаклы “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастанындагы (1394) геройлар язмышын да “Тамерлан манарасы” белән бәйләү бар. Шушы ук хезмәтендә Ф.Бәйрәмова бу төбәктәге Татар Варнасы авылы турында да яза. Биредә элек, нигездә, татарлар яшәгән. Мәсәлән, 1927 елда авылдагы 2394 кешенең 2312 се татар булган. Милли тормыш гөрләп торган. Ә хәзер, - ди автор, - “Варнадагы ун меңгә якын кешенең өчтән бере генә татар. Аларның да 50 яшьтән түбәннәре татарча укый-яза белми, яшьләрнең, балаларның күпчелеге татарча сөйләшми” (128 б.). Катнаш никахлар тулып ята... Аянычлы, фаҗигале хәлләр... Ә бу бит әле кайларда түгел, ә үзебезнең Уралда, Башкортостан, Татарстан һәм Казакъстанның борын төбендә.

Әле күптән түгел генә арабыздан киткән Миркасыйм Госмановның “Аксакаллар мәҗесеннән” исемле мәкаләсендә (11 нче сан) Нәкый ага Исәнбәт шәхесе һәм аңа мөнәсәбәттә шул чор милли тормышыны күп кенә сәхифәләре гәүдәләндерелә.

Журнал битләрендә “Татар энциклопедия” сеннән, “Авылларыбыз тарихы”ннан исемнәре астында даими бирелеп баручы материаллар да хуплауга лаек. Алар тарихи-мәдәни мирасны өйрәнүгә, хәтер дәвамчанлыгын тәэмин итүгә хезмәт итәләр. Нурмөхәммәд Хисамов мәкаләсендә (7 нче сан) үлемсез “Кыйссаи Йосыф” әсәре хакында күзәтү-тикшерүләр бергә җыйналып, гомумиләштерелеп бирелгән.

“Казан утлары” әдәбият-сәнгать һәм фән әһелләренең дә истәлекле көннәрен (юбилейларын) дә төрле шәкелдә, төрле рәвештә даими яктыртып бара. 2010 елда исә алар аеруча күп булды. Күптән түгел генә ачылган “Бәләкәйләр” рубрикасы да бик тиз үз укучыларын тапты.

Кыскасы, журнал, тормышның үзе кебек, шактый бай һәм эчтәлекле. Биредә исә без аның, алда әйтелгәнчә, бары тик кайбер якларына, анда басылган аерым язмаларга гына тукталдык. Бу мәҗмуга бик аз санлы, әмма

фидакарь затлар тарафыннан әзерләнә, дөньяга чыгарыла. Форсаттан файдаланып,аларга һәм журналның авторларына рәхмәт хисләрен юллыйк.

“Казан утлары”на берничә теләк-киңәш тә бар. 2010 елда аның битләрендә Рәфикъ Юныс һәм Рөстәм Зариповның бай эчтәлекле, үткен публицистик язмалары дөнья күрде. Бу төр материаллар күбрәк басылсын иде. Гали, Шыгырдан, Әләзән кебек республикабыздан читтәге зур татар авылларының милли тормышы да махсус язмаларга соралып тора. Журнал тышлыгында инде күп еллар буе әдипләрнең фотосурәтләре бирелеп бара. Бәлкем анда хәзерге Язучылар Берлеге әгъзаларын гына бирү шарт түгелдер. Элеккеге дәвер әдипләренең сурәтләрен дә тышлыкта урнаштыру зыян итмәс иде.

Мәҗмуга киңәш-теләкләр дигәндә, бер мәзәк искә килеп төште: Бер әби белән бабай табында ашап утыралар икән. Шул чак аштан чабата чыккан. Шунда әби: “И картым, бу чабата тегермән ташыннан ничек чыкты микән?” – дип куя. Бабай да аптырап калмый: “Тегермән ташы-тегермән ташы, ә менә иләктән ничек үтте микән ул?!” – дип җавап бирә. Шуның кебек, журналдагы текстлар тегермән ташлары, иләкләр аша кат-кат уза. Шулай да аерым сәхифәләрдә хосусый хата-кимчелекләр, техник җитешсезлекләр күзгә ташлана. Мәсәлән, “Данәгөл” романның 7 нче сан 11 нче битендә бер үк җөмлә механик рәвештә ике мәртәбә бирелгән. Хәтта сүзе “Божра буйлап” бәянының берничә битендә (11 нче сан, 74,76,77...) хаттә дип язылган. Бу чор төгәлсезлекләр башка урыннарда да очрап тора. Мәсәлән, 6 нчы санда: карван (96 б.) – кәрван, михман (96 б.) – миһман, ләтчит (104 б.) – ләчтит, имтиһан (115 б.) – имтихан, шөбхә (113 б.) – шөбһә һ.б. Аерым текстларда кабатланулар, билгеле әйберләрне артык җәелеп сөйләүләр дә күзгә ташлана. Язмаларны басмага әзерләгәндә, авторлар белән ачыклыйсы урыннар очрый. Мәсәлән, Р.Габделхакова романында Наргизә белән Янгураз мөнәсәбәтләренең бирелешендә эчке мантыйк, ышандыру көче җитеп бетми, сурәтләнгәннәр әкиятләргә охшап кала.

“Казан утлары” инде менә күп дистә еллар буе халкыбыз белән бергә атлый, аның киңәшчесе, сердәше, рухи-милли таянычы, остазы булып килә. Киләчәктә дә ул татарның иҗади китабы, әдәбиятыбызның мәркәзи мөнбәр - трибунасы булып калсын.

* * *

2010 елның 28 нче декабрендә “Казан утлары” редколлегиясенең киңәйтелгән утырышы булды. Анда, күренекле әдипләр, журнал хезмәткәрләре белән берлектә, хөкүмәт рәисенең урынбасары, мәдәният министры Зилә Вәлиева “Татмедиа” компаниясенең генераль директоры Айдар Сәлимгәрәев катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Утырышта сүз “Казан утлары” хакында гына түгел, ә гомумән бүгенге әдәбият, матбугат, милли мдәният турында да барды. Журналның 2010елгы саннарына төп күзәтүне Хатыйп Миңнегулов ясады. Әлеге мәкалә әнә шул доклад-чыгышка нигезләнгән.

Хатыйп Миңнегулов

6.01.2011